ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 040 от «25» 02 2021 г.

Муниципаль район башлыгының 2018 елның № 106 карары белән расланган Мамадыш муниципаль районының террорчылыкка каршы комиссиясе каршындагы «аерым игътибар» категориясендәге затлар белән эшләү буенча Ведомствоара эшче төркем турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Җирле үзидарә органнарының «Терроризмга каршы тору турында» 2016 елның 6 июлендәге 35-ФЗ номерлы Федераль законның 5.2 статьясында каралган вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында, «Экстремистлык эшчәнлегенә каршы тору турында» 2002 елның 25 июлендәге 114- ФЗ Федераль закон, терроризм һәм экстремизм идеологиясенә каршы торуга, экстремистлык һәм террорлык эшчәнлегенә җәлеп ителгән затларны адаптацияләүгә ярдәм итү, аларның агрессия дәрәҗәсен киметүгә, патриотик хисләрне актуальләштерүгә юнәлдерелгән профилактик чаралар комплексын оештыруга, шулай ук 2018 елның 28 августындагы 4 номерлы беркетмә белән расланган Мамадыш муниципаль районының террорчылыкка каршы комиссиясе карары нигезендә карар бирәм:

1. Муниципаль район башлыгының 2018 елның № 106 карары белән расланган Мамадыш муниципаль районының террорчылыкка каршы комиссиясе каршындагы «аерым игътибар» категориясендәге затлар белән эшләү буенча Ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Нигезләмәнең 10 пунктындагы 10 абзацындагы «Беркетмә карарлары «аерым игътибар» категориясендәге һәр гражданга аерым рәсмиләштерелә» сүзләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Беркетмә карарлары «аерым игътибар» категориясендәге һәр гражданга утырышта катнашкан комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора, рәис булмаганда комиссия рәисе урынбасарыныкы хәлиткеч була.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район башлыгы ярдәмчесе О. Ю. Рыловка йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы А.П.Иванов

000046